**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

01.07.2025 717-п

«Лето» РҮ» ДБУ «Хыял» балаларны савыктыру лагерында су алу корылмасының санитар саклык зоналарын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ санлы федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 санлы карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п санлы боерыгы нигезендә, 2018 елның 7 февралендәге җир асты байлыкларыннан файдалануга ТАТ ЗЛД серияле 01899 ВЭ лицензиясен, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килү турында 2025 елның 29 маендагы №16.11.11.000.Т.000819.05.25 санитар-эпидемиология бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук санитар саклык зоналарын оештыру проекты һәм җир кишәрлекләреннән файдалануны чикләүләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районында Ильинский авылыннан төньяк-көнчыгыштарак 1,4 км урнашкан «Лето» балаларны һәм яшьләрне савыктыру һәм ял итерүне оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең (алга таба – «Лето» РҮ» ДБУ) «Мечта» балаларны савыктыру лагерының (алга таба – «Мечта» БСЛ) җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык

зоналары проекты нигезендә боерык бирәм:

1. Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибы тарафыннан 2002 елның 26 февралендә расланган «Су белән тәэмин итү һәм эчә торган су үткәргечләрене чыганакларының санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә әлеге боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Ильинский авылыннан төньяк-көнчыгыштарак 1,4 км урнашкан «Лето» РҮ» ДБУ «Мечта» БСЛ җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләрен, әлеге боерыкның 2 нче кушымтасы нигезендә территориядән хуҗалыкта файдалану режимын билгеләргә.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Лето» РҮ» ДБУ;
- «Роскадастр» иҗтимагый-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына – санитар саклык зоналарын (алга таба – ССЗ) билгеләү турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетына;
- Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына.

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Ильинский авылыннан төньяк-көнчыгыштарак 1,4 км урнашкан «Лето» РҮ» ДБУ «Мечта» БСЛ җир астыннан су алу корылмасының ССЗ чикләре, су алу корылмасының ССЗ чикләрендәге территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру буенча чаралар үткәрүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына территориаль комплекслы схемаларны, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир төзелеше схемаларын, район планировкасы проектларын һәм территорияләрне үстерүнең генераль планнарын эшләгәндә ССЗ билгеләү турындагы карарны исәпкә алуны оештыру чараларын үткәрүне тәкъдим итәргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының
01.07.2025 ел, № 717-п
боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Ильинский авылыннан төньяк-көнчыгыштарак 1,4 км урнашкан «Лето» РҮ» ДБУ «Мечта» БСЛ җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләре

Хуҗалык-эчәр су белән тәэмин итү максатыннан «Лето» РҮ» ДБУ «Мечта» БСЛ җир астыннан су алу корылмасының җир асты байлыклары кишәрлеге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Ильинский авылыннан төньяк-көнчыгыштарак 1,4 км, «Лето» РҮ» ДБУ «Мечта» БСЛ төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан.

Су алу җайланмасы 1 номерлы файдалану скважинасыннан тора. Су алу скважинасының географик координатлары:

- 55°54'1,7256", 48°40'58,3405" (WGS - 84 координаталар системасы).

Санитар саклык зонасының беренче поясы астында урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:20:110805:225.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык сууткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

1 номерлы су алу скважинасы өчен ССЗ беренче поясы чиге гамәлдәге киртә буенча түбәндәге үлчәмнәр белән билгеләнә: скважина тамагыннан төньяктан - 30,25 м, көнчыгыштан - 29,15 м, көньяк-көнчыгыштан - 27,16 м, көньяктан - 29,99 м, көнбатыштан - 26,51 м;

Санитар саклык зонасының II поясы

1 номерлы су алу скважинасы өчен ССЗ икенче поясы чиге түбәндәге үлчәмнәрдә эллипс буларак билгеләнә: агым буенча өскә (төньякка) таба - 62 м, агым буенча аска (көньякка) таба - 29,99 м, максималь киңлеге - 76 м;

Санитар саклык зонасының III поясы

1 номерлы су алу скважинасы өчен ССЗ өченче поясы чиге түбәндәге үлчәмнәрдә эллипс буларак билгеләнә: агым буйлап өскә (төньякка) таба - 203 м, агым буйлап аска (көньякка) таба - 31 м, максималь киңлеге - 228 м.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының
01.07.2025 ел, № 717-п
боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Ильинский авылыннан төньяк-көнчыгыштарак 1,4 км урнашкан «Лето» РҮ» ДБУ «Мечта» БСЛ җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрне хуҗалык өчен файдалану режимы

1. Санитар саклык зонасының беренче поясы буенча чаралар

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар-саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган урыннарда урнашкан, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен, аларны чыгарганда су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналар бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.

## 3. Икенче пояс буенча чаралар

2 нче бүлектә күрсәтелгән чаралардан тыш, җир асты су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарындагы икенче пояс чикләрендә түбәндәге өстәмә чаралар үтәлергә тиеш:

3.1. Рөхсәт ителми:

зиратлар, үләт базлары, урыннарда санитария шартларын яхшырту кырлары, фильтрлаштыру кырлары, тирес саклау урыннары, силос траншеялары, терлекчелек һәм кошчылык предприятиеләре һәм җир асты суларын микроб белән пычрату куркынычы тудырган башка объектларны урнаштыру;

ашламалар һәм агулы химикатлар куллану;

төп кулланудагы урманнарны кисү һәм үзгәртеп кору.

3.2. Торак пунктлар һәм башка объектлар территорияләрен санитар төзекләндерү чараларын үтәү (канализация белән тәэмин итү, су үткәрми торган ташландык су чокыры ясау, өслек суларын читкә агызуны оештыру һ.б.).